Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№6 (60) Март, 2024 нче ел

2024 ГОД СЕМЬИ

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

Бу санда

Гимназия сулышы 2
Гаилә һәм мәктәп 3
Ана - шәфкать диңгезе 3
Гимназиядә Нәүрүз бәйрәме 4
Китап укыган бала акыллы, белемле, чиста күңелле була 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Гаилә һәм мәктәп - ышаныч җепләре





“Гаилә һәм мәктәп - ышаныч җепләре" муниципаль проекты кысаларында, гимназиянең медицина профилендә белем алучы 9 нчы в, 10 нчы б сыйныф укучылары, аларның ата-аналары, район башлыгы Альберт Хузин белән "Агач җимеше белән, кеше һөнәре белән матур" исемле Эшлекле очрашуда катнаштылар.

Укучылар, укытучылар коллективы кунакларны медицина профилендә белем алучы сыйныфларның эшчәнлеге белән таныштырды, район башлыгына укучыларга замана таләпләренә җавап бирерлек белем алу мөмкинлеге тудырганы өчен рәхмәтен җиткерде. Альберт Робертович биология кабинетының яңа җиһазлары белән танышты, укучыларның, ата-аналарның күпсанлы сорауларына җавап бирде.



### «Тамчы-шоу»да катнаштык

Безнең гимназия укучылары күптөрле мәктәп, район, республика, бөтенроссия күләмендә уздырылган бәйгеләрдә актив катнаша.

Бәйгеләрнең берсе – “ТНВ” каналында уздырыла торган “Тамчы-шоу” – интеллектуаль-күңел ачу бәйгесе.

Укучыларыбыз 2 нче март көнне Казан шәһәрендә "Тамчы-шоу" интеллектуаль бәйгесендә уңышлы чыгыш ясадылар. Гимназиянең 7 нче сыйныф укучыларыннан торган "Татулар" һәм 8 нче сыйныфлардан "Кәттә кешеләр" командалары катнашты. "Татулар" командасын Галимова Айназ, Гизетдинов Данис, Мадьярова Мәрьям, "Кәттә кешеләр"не Бәдертдинов Булат, Биккинина Наилә, Харитонов Данил тәкъдим итте.

Укучылар төрле фәннәрдән белемле һәм тапкыр булуларын күрсәттеләр. "Кәттә кешеләр" командасы "Татулар"дан 3 баллга гына калышты. Укучыларны "Тамчы-шоу" уенына тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ямалова Г.Ф., социаль педагог Әмирова М.Р., педагог-китапханәче Солтанова Г.М. әзерләде.





# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## «Пушкин укулары» бәйгесе



20 нче мартта Яр Чаллының А.С.Пушкин исемендәге 78 нче номерлы лицеенда Бөтенроссия “Пушкин укулары” иҗади бәйгесе узды.

Конкурста гимназия укучылары да катнашты, алар «Сәхнә осталыгы» секциясендә төрле яшь категорияләрендә чыгыш ясадылар.

11 нче сыйныфлардан торган иҗат коллективы А.С.Пушкинның “Евгений Онегин” әсәрен сәхнәләштереп беренче дәрәҗә дипломга лаек булды, 5 нче б сыйныфы укучысы Закиров Искәндәр һәм 11 нче сыйныф укучысы Идиятуллина Сабина беренче дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнделәр, 5 нче б сыйныф укучысы Солтанов Рияз икенче дәрәҗә Дипломга ия булды.

Җитәкчеләре - рус теле һәм әдәбияты укытучысы Хәйруллина Чулпан Алмазовна.

## “Илһам” Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе



22 нче март көнне "Мизгел" яшьләр үзәгендә “Илһам” Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең зона туры үтте. Конкурста Мөслим, Минзәлә, Зәй, Сарман, Бөгелмә, Ютазы һәм Лениногорск районнарыннан яшь язучылар катнашты. Чара барышында илледән артык баланың чыгышлары тыңланды. Аларны күренекле язучылардан торган мәртәбәле жюри бәяләде. Яшь язучылар проза, поэзия һәм журналистика жанрларында үзләренең иҗат җимешләрен тәкъдим иттеләр.

Гимназиянең 6 нчы а сыйныфы укучысы Гәрәев Данис, 7 нче в сыйныфыннан Зәкиева Әминә, 5 нче а сыйныфыннан Мирзамуратов Рәйхан "Илһам" бәйгесендә катнашып, беренче тур җиңүчеләре исеменә лаек булдылар.

Укытучылары: Ямалова Г.Ф, Мирзамуратова Г.М., Солтанова ГМ., Авзалова З.З.

## Орел шәһәреннән җиңү белән...

Гимназиянең 11 нче сыйныф укучысы Бариева Илина, армрестлинг буенча РФ чемпионы! Илинабыз Икенче тапкыр РФ спорт мастеры нормативын үтәде. 8 нче а сыйныфы укучысы Зиннурова Илзирә армрестлинг буенча Россия Беренчелегенең бронза призеры булды! Укучы кызларыбыз белән горурланабыз! Алга таба да җиңүләр сезгә - Илина, Илзирә!



## Фәнни конференциядән җиңү белән



22 нче март көнне Казан шәһәрендә уздырылган Туфан Миңнуллин исемендәге фәнни-гамәли конференциядә катнашып, гимназиянең педагог-китапханәчесе Солтанова Гөлшат Марс кызы икенче урынга, 11 нче сыйныф укучысы, "Тылсым+" газетасы мөхәррире Минһаҗева Камилә журналистика секциясендә өченче урынга лаек булды.

Җиңүчеләрне котлыйбыз! Алга таба да уңышлар юлдаш булсын!

## Алдынгылар хәрәкәте “Мизгел”яшьләр үзәгендә

Тәрбия эшләре буенча директор киңәшчесе Солтанова Л.Р. һәм Мөслим гимназиясе алдынгылар хәрәкәте активистлары "Мизгел" яшьләр үзәгендә Кырымның Россия белән берләшүенең 10 еллыгына багышланган "Своя игра" интеллектуаль викторинасын оештырдылар.



# 2024 ЕЛ – ГАИЛӘ ЕЛЫ

## Гаилә һәм мәктәп

2024 нче ел Россиядә Гаилә елы дип игълан ителде. Гаилә – һәркем өчен иң кадерле сыеныр урын. Гаиләләр тату, әти-әниләр һәм балалар сәламәт булганда, авырлыкларны җиңү авыр түгел. Матур гаилә коруның да сере гади: өйдәге һәр кеше бер-берсен аңлап, хөрмәт итеп яшәсә, шул җитә.

Гаилә ул – якты матур йорт, балалар бакчасы, мәктәп. Шулар арасында бердәмлек булса, балаларга тиешле тәрбия биреп була. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дисәләр дә, бала күп вакытын бакча белән мәктәптә уздыра. Димәк, мәктәп тә әти-әни белән бергә балаланы очарга өйрәтергә тиеш.

Гаилә елы уңаеннан, “Гаилә һәм мәктәп - ышаныч җепләре” муниципаль проектына нигезләнеп, Мөслим гимназиясенең 3 нче сыйныф укучылары әти-әниләре белән берлектә “Җитәкче белән иртәнге аш” исемле күңелле очрашу уздырдык. Укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Лилиана Миннегалиева Гаилә елы белән котлады. Дәрестә балаларның сәламәтлегенә басым ясалды, телефон-гаджетларның балаларга зыяны турында кисәтелде. Гимназиядә спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләрнең күп булуы әйтелде.

Очрашу спортзалда “Күңелле эстафета” уены белән дәвам итте. Параллель өч сыйныфтан һәм әти-әниләрдән торган дүрт команда төрле ярышларда катнашып, күңелле ял иттеләр.




Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: гаилә белән мәктәп бердәм булып, кулга-кул тотынышып эшләгәндә генә уңышларга ирешеп була.

***Миләүшә Хәсәнова,***
***башлангыч сыйныфлар укытучысы***

# АНА — ШӘФКАТЬ ДИҢГЕЗЕ

## *Әнием*

*Минем әнием иң матур һәм иң акыллы әни. Иртән ул мине “йомшагым”, - дип уята. Тәмле чәйләрен ясый, чәчемне үрә. Уңышлар теләп мәктәпкә озата.*

*Без кайтуга тәмле ризыклар пешереп тора. Мин аны бик яратам. Әни – дөньяда иң бөек кеше!*

***Шабаева Мәрьям***

***

*Минем әни бик нык кайгыртучан. Ул бик тәмле пешерә. Әнием бухгалтер булып эшли.*

*Ул эшләргә бик ярата. Без кызлары белән серләшергә дә вакыт таба. Мин әниемне бик яратам.*

***Хәбибуллина Алия***

*Әни – җирдә иң газиз якын кеше. Миңа әнием бик кадерле. Аның исеме Ләйсән. Ул бик әйбәт. Сабыр. Тыйнак. Мин әниемә булышам. Аны борчымаска тырышам. Әни минем сорауларыма да җавап таба. Үзенең киңәшләрен бирә. Ул әле тәмле итеп ашарга да пешерә.*

*Мин әниемне хөрмәт итәм. Бик нык яратам.*

***Хөсәенов Айзат***

***

*Ана, әнкәй, әнкәем, әни – күпме мәгънә бу сүз-ләрдә. Җир йөзендә иң газиз, иң кадерле гүзәл зат бит ул әни! Шул сүз белән безнең телебез ачыла.*

## *2 нче а сыйныфы укучылары яза*

*Чынлап та якты дөньяга аваз салгач та, безне йомшак куллары белән сыйпап, бишек җырларын көйләп, иркәләп назлаучы да әни!*

*Минем әнием дә иң гүзәл әниләрнең берсе! Без аны бик нык яратабыз һәм хөрмәт итәбез. Ул безнең кинәшчебез дә, җилдавылдан саклаучыбыз, яклаучыбыз да. Ул барысына җитешә. Матур гөлләр үстерә. Тәмле ашлар пешерә. Безне дә чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтә. Мин әнием белән горурланам.*

***Солтанова Амилия***

## Сәламәтлек көне

Гаилә елы кысаларында, 16 нчы мартта, әти-әниләр белән бергә, гимназия укучылары “Сәламәтлек көне” уздырды. Бу чарада һәр класс актив катнашты. Язгы матур көнне кемдер әти-әниләре белән чаңгыда йөрде, кемдер тау шуды, кемдер кайнар чәй һәм тәмле ризыклар белән сыйланды. Һәркемгә саф һавада гаилә белән бергә йөрү бик ошады!



## "Олимпия уеннары" бәйрәме

Гаилә елы уңаеннан Мөслим гимназиясенең 6 нчы б, 7 нче в сыйныф укучылары һәм ата-аналары өчен мавыктыргыч конкурс программасы - "Олимпия уеннары" үткәрелде! Чараның төп максаты җиңү түгел, ә якыннары белән бергә катнашу һәм күңел ачу, сыйныф коллективын һәм ата-аналар коллективын берләштерү.



## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЙОЛАЛАРЫ, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ

### Гимназиядә Нәүрүз бәйрәме



Нәүрүз - халыкның кышны озатуы, язны каршылау бәйрәме. Бу бәйрәм борынгыдан ук килгән. Нәүрүз бәйрәме хәзер дә бәйрәм ителә, бу көнне балалар йорттан йортка кереп, Нәүрүз такмагын әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләгәннәр. Хуҗалар исә, ботка өчен ярма, йомырка, май биргән.

Нәүрүз 21 нче март - язгы көн белән төн тигезләшкән көнне билгеләп үтелә. Нәүрүз фарсы теленнән "Яңа көн" дигәнне аңлата.

21 нче мартта гимназиядә "Нәүрүз" бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмне 10 нчы сыйныф укучылары башлангыч сыйныф укучылары белән үткәрде. Бәйрәмнең хуҗасы Нәүрүзбикә килеп, Кар кызы белән көч сынашты. Чөнки Кар кызының үз



урынын Нәүрүз кызына бирәсе килми иде. Әлбәттә инде Нәүрүз кызы бу ярышларда җиңеп чыкты. Ул матур теләкләр әйтеп, бәйрәм кунакларын котлады. Бәйрәм күңелле ярыш-уеннар белән дәвам итте, укучылар канәгать калды.

## КИТАП УКЫГАН БАЛА АКЫЛЛЫ, БЕЛЕМЛЕ, ЧИСТА КҮҢЕЛЛЕ БУЛА

### *25-30 март балалар китабы атналыгы*

***Галимнәр һәр татар баласы укырга тиешле 100 китап исемлеген төзегән. Китапларның беразын булса да укучылар укысын иде дигән теләктә исемлекне тәкъдим итәбез.***

#### Башлангыч сыйныф укучыларына:

1. Абдулла Алиш. Ана әкиятләре.
2. Резеда Вәлиева. Нәниләр китабы / Ак песи (җыентыклар).
3. Шәүкәт Галиев. Шәвәли хәйләсе : шаян шигырьләр.
4. Галимҗан Гыйльманов. Әбием сихерче бугай (җыентык).
5. Рәфис Корбан. Тапкырларга табышмак (җыентык).
6. Рөстәм Мингалим. Галстуклы кәҗә (җыентык).
7. Роберт Миңнуллин. Сөенсеннәр әле сабыйлар (җыентык).
8. Хәкимҗан Халиков. Иң гадел дус (җыентык).
9. Халык иҗаты: әкиятләр.
10. Халык иҗаты: мәкальләр һәм әйтемнәр.
11. Халык иҗаты: табышмаклар.

#### 5-9 нчы сыйныф укучыларына:

12. Гамил Афзал. Рәхмәт (җыентык).
13. Мирсәй Әмир. Миңнекамал.
14. Фатих Әмирхан. Ай өстендә Зөһрә кыз.
15. Габдрахман Әпсәләмов. Алтын йолдыз.
16. Фәүзия Бәйрәмова. Кыңгырау / Алыплар илендә
17. Ибраһим Гази. Тургай картаямы икән?
18. Мәҗит Гафури. Шигырьләр / Кара йөзләр.
19. Нәбирә Гыйматдинова. Сихерче / Сәвилә.
20. Дәрдмәнд. Агарган кыл (җыентык)
21. Нәҗип Думави. Су кызы / Болгар кызы Тойгы туташ.
22. Әмирхан Еники. Тауларга карап / Уяну.
23. Нәкый Исәнбәт. Хуҗа Насретдин.
24. Ләбибә Ихсанова. Тузганак (хикәяләр җыентыгы)
25. Галиәсгар Камал. Безнең шәһәрнең серләре.
26. Фатих Кәрим. Поэмалар.
27. Ләбиб Лерон. Чыктым аркылы күпер (җыентык).
28. Шәйхи Маннур. Поэмалар / Чын сөю бармы?
29. Каюм Насыйри. Кырык вәзир.
30. Рифә Рахман. Бер микъдар былбыл / Сөннәтче әби.
31. Шамил Рәкыйпов. Кызлар–йолдызлар.
32. Сәгыйть Рәмиев. Сызла, күңелем! (җыентык)
33. Габделхәй Сабитов. Хикәяләр.
34. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр (җыентык).
35. Хәсән Туфан. Кайсыгызның кулы җылы? (җыентык)
36. Равил Фәйзуллин. Якты моң / Җил – вакыт ул (җыентыклар).
37. Сибгат Хәким. Сусау (җыентык).
38. Халык иҗаты: риваять һәм легендалар.
39. Халык иҗаты: эпос-дастаннар.
40. Халык иҗаты: бәетләр һәм мөнәҗәтләр.

#### Югары сыйныф укучыларына:

41. Гариф Ахунов. Чикләвек төше / Идел кызы.
42. Мөдәррис Әгъләм. Кан тамырын кистем (җыентык).
43. Рәшит Әхмәтҗанов. Ачлык мәйданы (җыентык).
44. Роберт Әхмәтҗан. Таш аргамак (җыентык).
45. Харрас Әюп. Йөз яктысы (җыентык).
46. Рабит Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк / Сөембикә.
47. Салих Баттал. Олы юл буйлап / Чирмешән якларында.
48. Әхсән Баян. Яшьлегемне эзлим / Урланган ай.
49. Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә.
50. Хәй Вахит. Туй алдыннан.

***Дәвамы апрель санында***

ТЫЛСЫМ+
Март, 2024 нче ел
№6 (60)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Мингазова Камилә
**Корректорлар:** Мингазова Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыйпов Илназ, Хаертдинов Ранис

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100